Национальная
библиотека
Республики Татарстан

# БАР ҖЫРЫМНЫ ИЛГӘ БАГЫШЛАДЫМ...

Татар халкының мәшһүр улы,
каһарман-шагыйрь Муса Җәлилнең
(Муса Мостафа улы Җәлилов; 1906–1944)
тууына 120 ел тулуга багышланган
методик-библиографик ярдәмлек

Казан
«Милли китап» нәшрияты
2025

Татарстан Республикасы Милли китапханәсе

# БАР ҖЫРЫМНЫ ИЛГӘ БАГЫШЛАДЫМ...

Татар халкының мәшһүр улы, каһарман-шагыйрь
Муса Җәлилнең (Муса Мостафа улы Җәлилов; 1906–1944)
тууына 120 ел тулуга багышланган
методик-библиографик ярдәмлек

Казан
«Милли китап» нәшрияты
2025

**УДК 025.5+821.512.145(092)**
**ББК 78.373.8:83.3+83.3(2=632.3)-8**
**Б 23**

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең
редакция-нәшрият шурасы карары белән басыла

Төзүчесе Р.Р.Гаязова

Мөхәррире И.Г.Һадиев

**Б 23** Бар җырымны илгә багышладым...: татар халкының мәшһүр улы, каһарман-шагыйрь Муса Җәлилнең (Муса Мостафа улы Җәлилов; 1906–1944) тууына 120 ел тулуга багышланган методик-библиографик ярдәмлек/ Татарстан Респ. Милли к-ханәсе; төз. Р.Р.Гаязова; мөх-ре И.Г.Һадиев. – Казан: Милли китап, 2025. – 48 б.

Ярдәмлек Муса Җәлилнең үз әсәрләре, аның тормыш юлына һәм иҗатына багышланган әдәбият белән эшләү өчен китапханәчеләргә тәкъдим ителә. Җыентыкта әдәби кичә һәм уен-кичә үрнәкләре, китапханәчегә киңәшләр һәм әдәбият исемлекләре бирелә.

**УДК 025.5+821.512.145(092)**
**ББК 78.373.8:83.3+83.3(2=632.3)-8**

© Татарстан Республикасы Милли китапханәсе, 2025;
© «Милли китап» нәшрияты, 2025.

## Кереш сүз

Мин кабыздым җырда ялкын итеп
Йөрәгем һәм хаклык кушканны.
Җырым белән дусны иркәләдем,
Җырым белән җиңдем дошманны.
*М.Җәлил. «Җырларым»*

2026 елның 15 февралендә татар халкының каһарман улы, мәшһүр шагыйрь Муса Җәлилнең (Муса Мостафа улы Җәлилов; 1906–1944) туууына 120 ел тула.

Муса Җәлил 1906 елның 15 февралендә элекке Оренбург губернасы (хәзерге Оренбург өлкәсе Шарлык районы) Мостафа авылында крестьян гаиләсендә алтынчы бала булып дөньяга килә. 1913 елда Мусаның әтисе Мостафа абзый, ишле гаиләсен ияртеп, Оренбург шәһәренә күчә һәм вак-төяк сату эшләре белән шөгыльләнә башлый. 1918 елны ул туган авылына кире кайта һәм бер елдан шунда вафат була.

Муса алты яшеннән авыл мәктәбенә укырга керә, гаилә шәһәргә күчкәч, укуын «Хөсәения» мәдрәсәсендә дәвам иттерә. Мәдрәсә елларында (1914–1917) матур әдәбият әсәрләрен яратып укый, Тукай, Дәрдмәнд, С. Рәмиев иҗатлары белән якыннан таныша, шулар тәэсирендә үзе дә шигырьләр язып, аларны мәдрәсәдәге кульязма журналга урнаштыра бара.

Октябрь революциясе җиңеп, илдә совет власте урнашкач, «Хөсәения» мәдрәсәсе Мәгариф комиссариаты карамагындагы урта педагогик белем бирү мәктәбе итеп үзгәртелә. Муса, бу мәктәпнең алдынгы укучыларыннан булып, озакламый шәһәр комсомол оешмасына әгъза булып керә.

1919 елның октябрендә, Оренбург шәһәре Дутов гаскәрләре тарафыннан камап алынган чорда, Төркестан фронты политидарәсе органы «Кызыл йолдыз» газетасында унөч яшьлек Муса Җәлилнең «Бәхет» исемле шигыре басылып чыга. Шуннан соң аның революция, көрәш рухы белән сугарылган романтик шигырьләре матбугат битләрендә еш күренә башлый. 1919 елның декабрендә Муса Җәлил туган авылы Мостафага кайта һәм мәктәп балаларын, яшүсмерләрне

бердәм оешмага туплау буенча культура-агарту эшләре алып бара. 1920 елның гыйнварында Муса Җәлилнең актив катнашы белән Мостафа авылы яшьләренең комсомол ячейкасы төзелә. Шушы ук вакытларда ул ирекле коммунарлар отряды составында, кулына корал алып, совет хакимиятенә каршы булган бандаларны тар-мар итү операцияләрендә катнаша.

1921 елның афәтле җәен Муса Җәлил яңадан Оренбург шәһәрендә уздыра. Көзен аны, партиянең губерна комитеты рекомендациясе белән, Оренбург хәрби-партия мәктәбенә урнаштыралар. Алты айдан мәктәпне тәмамлагач, ул Халык мәгарифе институтына укырга керә, ләкин, авырып китеп, тиздән укуын ташларга мәҗбүр була. Аннан да бигрәк ул Казанга, татар мәдәниятенең үзәгенә ашкына.

1922 елның көзендә Муса Җәлил Казанга килә. Башта ул «Татарстан» газетасы редакциясендә эшли, ә 1923 елдан Татрабфакта укый башлый. Рабфакта төрле фәннәрнең нигезләре белән танышу, алдынгы яшьләр, язучылар арасында кайнау Муса Җәлилнең фикри үсешенә һәм иҗат активлыгына уңай йогынты ясый. Газета-журналларда аның бер-бер артлы шигырьләре, мәкаләләре басыла, 1925 елда исә «Барабыз» исемле беренче шигъри җыентыгы дөнья күрә.

1925–1927 елларда Муса Җәлил ВЛКСМның Орск өяз комитетында, аннары Оренбург губерна комитетында инструктор булып эшли. 1927 елда аны комсомолның Бөтенсоюз киңәшмәсенә делегат итеп җибәрәләр. Киңәшмәдә ул ВЛКСМ Үзәк Комитетының татар-башкорт секциясе бюросына әгъза итеп сайлана һәм Мәскәүдә эшләргә калдырыла. Бюроның тапшыруы буенча Муса Җәлил беренче татар совет балалар журналларын («Кечкенә иптәшләр» һәм «Октябрь баласы») оештыруда актив катнаша һәм 1932 елның ахырына кадәр («Октябрь баласы» Казанга күчеп, «Пионер каләме» исеме белән чыга башлаганчы) шул журналларның җаваплы редакторы булып эшли. Бер үк вакытта ул 1927–1931 елларда I Мәскәү дәүләт университетының әдәбият-сәнгать факультетында укып югары белем ала.

1933–1934 елларда Муса Җәлил Мәскәүдә татар телендә чыга торган «Коммунист» газетасының әдәбият-сәнгать бүлеген җитәкли. Үзәк газеталарда эшләгән елларда ул, журналист-хәбәрче буларак, күп кенә промышленность предприятиеләренә, колхоз-совхозларга бара, халыкның тормышы һәм хезмәте белән якыннан таныша. Болар һәммәсе аның әдәби иҗатында билгеле бер чагылыш табалар. 1934

елда шагыйрьнең күп кенә шигырьләрен эченә алган шактый зур җыентыгы («Орденлы миллионнар») басыла һәм шул ук елны «Стихи Мусы Джалиля» исеме белән сайланма шигырьләре беренче мәртәбә рус телендә чыга.

1935 елда Мәскәү дәүләт консерваториясе каршында татар опера театрына профессиональ кадрлар әзерләү өчен Татар опера студиясе оештырылгач, Муса Җәлилне шунда әдәби бүлек мөдире итеп эшкә чакыралар. Шагыйрь үзе өчен яңа бу хезмәткә дәртләнеп тотына, чагыштырмача кыска гына вакыт эчендә опера сәнгатенең специфик үзенчәлекләрен, классик опера һәм балет либреттоларының язылу хасиятләрен профессиональ белгеч дәрәҗәсендә үзләштереп, студиядә зур оештыру эшләре алып бара: үз тирәсенә дистәләрчә шагыйрьләрне һәм композиторларны туплый, аларны сәнгатьнең катлаулы тармагында иҗат итәргә рухландыра, либреттолар язарга булыша, беренче татар операларының тууына турыдан-туры иҗади ярдәмен күрсәтә. 1938 елда студиядә укуын тәмамлап Казанга кайткач та Муса Җәлил опера театрының әдәби бүлек җитәкчесе булып эшләвен дәвам иттерә.

Муса Җәлилнең 1934–1941 еллар арасында язган лирик шигырьләре, җырлары, «Хат ташучы» (1938), «Алтынчәч» кебек поэмалары сугышка кадәрге татар совет поэзиясенең үзенчәлекле бер казанышы буларак тәкъдир ителәләр.

1939 елда Муса Җәлил Татарстан Язучылар союзы идарәсенең җаваплы секретаре итеп билгеләнә. Шул ук елны Казан хезмәт ияләре аны шәһәр советына депутат итеп сайлыйлар. Ватан сугышын ул шушы җаваплы постларда эшләүче җәмәгать эшлеклесе һәм күренекле әдип сыйфатында каршылый.

1941 елның июль аенда Муса Җәлил армиягә алына. Башта ул Казан гарнизоны хәрби частендә рядовой кызылармеец булып хезмәт итә, аннары Курск өлкәсендәге политработниклар әзерли торган алты айлык курсларга укырга җибәрелә. Курск өлкәсенә фашист гаскәрләре якынлашкач, курслар Татарстанның Минзәлә шәһәренә эвакуацияләнә. 1941 елның декабрендә курсларны тәмамлагач, өлкән политрук Муса Җәлил Мәскәү аша фронтка китә (1942 елның феврале). Ул Төньяк-Көнбатыш фронтта чыга торган «Отвага» исемле газетаның алгы сызыктагы хәрби корреспонденты итеп билгеләнә. 1942 елның июнендә Волхов юнәлешендә барган канлы сугышлар вакытында, аларның часте чолганышта калып, Муса Җәлил каты

яраланган хәлендә дошман кулына эләгә. Шул көннән патриот шагыйрьнең фашист тоткынлыгындагы газаплы һәм героик тормыш этабы башлана.

Муса Җәлил һәм башка көрәштәшләре дошман төрмәсендә яшерен оешма төзеп, фашистларга каршы эш алып бара башлый, «Идел-Урал» легионындагы әсирләргә листовкалар таратып, аларны үзебезнекеләр ягына чыгарга өнди – берничә батальон, шул рәвешчә, сугыш кырына барып җиткәч партизаннарга кушыла. Җәлил һәм аның иптәшләре ахыргы сулышларына кадәр ватан алдында турылыклы булып калалар һәм фашизмга каршы көрәштә тиңдәшсез рухи ныклык, батырлык үрнәге күрсәтәләр.

1944 елның февраль аенда Җәлилгә һәм аның көрәштәшләренә Дрезденда суд була. Фашистик хәрби суд аларны, «дәүләткә каршы җимерү эше» алып баруда гаепләп, үлем җәзасына хөкем итә. Шул елның 25 августында Плетцензее төрмәсендә унбер җәлилченең гомере өзелә.

Советлар Союзында да Муса Җәлил Ватанына хыянәт итүдә гаепләнә, тоткынлыкта чакта язган шигырьләре тупланган Моабит дәфтәрләре туган ягына әйләнеп кайткач кына аның исеме әлеге «сатлыкҗан» дигән кара тамгадан арына.

Бөек Ватан сугышында немец-фашистларга каршы көрәштә күрсәткән батырлыгы өчен, 1956 елның 2 февралендә СССР Верховный Советы Президиумы Указы нигезендә, Муса Җәлилгә (үлгәннән соң) Советлар Союзы Герое дигән мактаулы исем бирелде, ә әсирлектә тудырган поэтик иҗаты – бөтен дөньяга мәшһүр «Моабит дәфтәрләре» Ленин премиясенә лаек булды.

Шагыйрьнең әсәрләре хәзерге вакытка авар, албан, азәрбәйҗан, әрмән, балкар, башкорт, белорус, венгр, грузин, инглиз, казакъ, калмык, каракалпак, корея, кыргыз, кытай, латыш, ләзги, литва, мари, молдаван, немец, рус, таҗик, төрек, төрекмән, тыва, удмурт, украин, үзбәк, чех, чуваш, эстон, якут һәм башка телләргә тәрҗемә ителгән.

Муса Җәлилнең тормышына һәм иҗаттагы батырлыгына багышлап йөзләрчә мәкаләләр, фәнни хезмәтләр, монографияләр язылган, шигырьләр, поэмалар, романнар, драмалар һәм башка сәнгать әсәрләре иҗат ителгән. Алар арасында, мәсәлән, Шәйхи Маннурның «Муса» (1968), Габдрахман Әпсәләмовның «Агыла болыт» (1977), Рафис Корбанның «Ватан» (2018) романнары, Нәкый Исәнбәтнең «Муса Җәлил» (1956), Риза Ишморатның «Үлмәс җыр» (1955), Туфан

Миңнуллинның «Моңлы бер җыр» (1981) драмалары, Сибгат Хәкимнең «Торыгыз, Мусалар», «Немец дәфтәреннән» исемле шигъри цикллары, Әнвәр Давыдовның «Муса абый» повесте (1964), Нәҗип Җиһановның Әхмәт Фәйзи либреттосына язылган «Җәлил» операсы (1957) һәм башка сәнгатькярләрнең Муса Җәлил образына багышланган күп әсәрләре бар. 1956 елда Татар дәүләт опера һәм балет театрына Муса Җәлил исеме бирелә. 1966 елда Казан Кремле каршындагы мәйданда, 2012 елда Мәскәүдә Муса Җәлил урамында каһарман шагыйрьгә һәйкәлләр куела. 1968 елда Муса Җәлил исемендәге Республика яшьләр премиясе булдырыла. 1970 елда Минзәлә шәһәрендә шагыйрьнең мемориаль музее, 1983 елда Казанда музей-квартирасы ачыла.

Соңгы дистә ел дәвамында Бөтендөнья татар конгрессы инициативасы белән Казахстанның Сәмәй һәм Усть-Каменогорск шәһәрләрендә, Россиянең Әстерхан, Курган, Якутск шәһәрләрендә, Адыгея Республикасында, Свердловск, Чиләбе өлкәләрендә Муса Җәлилгә һәйкәл-бюстлар ачылды.

«Җәлил укулары» Халыкара әдәби конкурсы елдан-ел киңрәк колач ала бара, 2025 елда ул сигезенче тапкыр үткәрелә һәм конкурста җиңүчеләр катнашында гала-концерт 2026 елның февраль аенда Казан шәһәрендә узачак.

Муса Җәлил юбилеен ел дәвамында китапханәләрдә билгеләп үтәргә, ярдәмлектә бирелгән материаллардан, әдәбият исемлегеннән файдаланып төрле чаралар: искә алу кичәсе, Интернет челтәрендә акцияләр, әдәби һәм шигъри батллар, сорау-җавап кичәсе, тукталышлы укулар, айлыклар яки атналыклар, фикер алышулар, әңгәмәләр, интеллектуаль уеннар һ.б. чаралар үткәрергә киңәш итәбез.

Шулай ук чараларны әзерләгәндә һәм үткәргәндә Муса Җәлилгә багышлап төзелгән, Татарстан Республикасы Милли китапханәсе сайтында (https://kitaphane.tatarstan.ru/tat/jal.htm) урнаштырылган биобиблиографик белешмәлектән материаллар: язучының тормыш юлына һәм иҗатына багышланган мәкаләләрне, фотосурәтләрне, сценарийларны, аның әсәрләрен, әдәбият исемлекләрен, Интернетта Муса Җәлилгә багышланган сайтларга сылтамалардан файдаланырга мөмкин.

## Гасырларда калыр батырлык

*(Муса Җәлилне искә алу кичәсе)*

*Кичә язучының иҗатташлары, хезмәттәшләре, замандашларының хатирәләренә нигезләнеп төзелә. Күрсәтелгән чыганакларда тупланган истәлекләрне, хатларны, Муса Җәлилнең шигырьләрен 2 укучы чиратлашып укыйлар. Истәлекләр арасында музыкаль тәнәфесләр оештырырга, аның шигырьләренә язылган җырларның язмаларын тыңларга киңәш итәбез.*

*Чараны башлар алдыннан, Муса Җәлилнең биографиясе белән таныштыру өчен, Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты тарафыннан төшерелгән видеоязманы экранда күрсәтергә тәкъдим итәбез (түбәндәге сылтама буенча:* https://tatarica.org/ru/razdely/kultura/literatura/personalii/dzhalil-musa).

**Файдалану өчен әдәбият исемлеге:**


1. Муса турында истәлекләр / төз. Р.Ә. Мостафин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 319 б.
2. Муса турында истәлекләр / төзүчесе һәм әдәби эшкәртүчесе Гази Кашшаф. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. – 312 б.
3. Хамматов Ш. Муса Җәлил, аның каләмдәшләре / Ш.Хамматов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 207 б.
4. Үлмәс җыр: Муса Җәлил турында җыентык / төзүчесе Р. Мостафин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1971. – 247 б.
5. Үлемсезлек таңында: Муса Җәлил турында истәлекләр / [ред. Г. Кашшаф]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1971. – 102 б.
6. Мостафин Р. Өзелгән җыр эзеннән: әдәби-документаль повесть / Р. Мостафин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 438 б.
7. Мостафин Ш. Алар – Җәлил-Кормаш йолдызлыгыннан! / Ш. Мостафин. – Казан: Сүз, 2017. – 142 б.
8. Шамов А. Ике очрашу: [шагыйрь М.Җәлил тур. истәлекләр] / А. Шамов // Мәйдан. Чаллы. – 2016. – № 2. – Б. 28–33.
9. Муса Җәлил – документларда / төз. Р.Исламов. – Казан: Җыен, 2021. – 832 б.

**Муса Җәлил – герой-шагыйрь»**

*(уен-кичә)*

*Залның түренә Муса Җәлилнең иҗатын чагылдырган, аның төрле елларда басылып чыккан китапларыннан һәм аның турындагы истәлекләрдән төзелгән китап күргәзмәсе куела, кечкенә 2 өстәл урнаштырыла. Түргә экран эленә. Кичәгә презентация әзерләнә.*

*Уенда 4 кешедән торган 2 команда катнаша. Уен-ярышны бәяләргә жюри сайлана. Чарага әзерлек алдыннан Муса Җәлилнең иҗаты һәм әсәрләре белән танышу мөһим. Уен ахырында жюри уенның нәтиҗәләре белән таныштыра, җиңүчеләрне бүләкли.*

*(Залга алып баручы һәм 2 укучы чыгалар).*

**А.б.** Хәерле көн, исәнмесез, бәйрәмебезнең хөрмәтле кунаклары!

Бүген, Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты, татар халкының батыр улы, патриот-шагыйрь Муса Җәлилнең тууына 120 ел тулу уңаеннан, «Муса Җәлил − герой-шагыйрь» дигән уен-кичәгә җыелдык.

**1 нче укучы.** Муса Җәлил дигәндә – татар халкын, ә татар халкы дигәндә – Муса Җәлилне күз алдына китерәләр. Аның шәхесен һәм батырлыгын бөтен дөнья белә. Димәк, ул – чын мәгънәсендә халкыбызның бөек шәхесе, горурлыгы.

**2 нче укучы.** Муса Җәлил поэзиясе иң олы һәм гадел хөкем саналган вакыт сынавын узды. Бу олы мирас хәзергәчә сугышчан рухын, сәнгатьчә матурлыгын саклый, XXI гасыр кешесен дә сокландыра һәм яшәүгә рухландыра, тынычлык, иминлек сагында тора.

**1 нче укучы.** Муса Җәлил – «Моабит дәфтәрләре» белән милли шигъриятне дөнья киңлекләренә чыгарган, кыска гомерендә үзеннән соңгы буыннарга үлмәс иҗат калдырган, яшәү мәгънәсен туган халкына хезмәттә күргән, аны батыр йөрәкле, үлмәс җанлы итеп таныткан, Ватан азатлыгы хакына газиз җанын биргән, язмыш сынауларына бирешмичә, үлемен батырларча кабул иткән көчле рухлы шәхес.

**2 нче укучы.** Муса Җәлил фашизмның кешелек дөньясына алып килгән фаҗигасен үз күзләре белән күрде, үз тәнендә, үз җанында татыды.

**1 нче укучы.**

Үзем күрдем, үз күзләрем белән
Үкреп акты ничек елгалар,
Балалар күк ничек үкси-үкси
Яшен түкте ярсып җир ана.

Үзем күрдем, ничек моңлы кояш
Болыт аша җиргә сузылып,
Үксеп үпте үксез балаларын
Соңгы кабат кысып, суырып.

**2 нче укучы.** Бу фаҗигадә шагыйрь рухи җиңеп чыгуына, дошманның тар-мар ителүенә ышана.

**1 нче укучы.**

Беләм, ләкин яшәү килмәс миңа,
Бар хыялым шунда табылыр.
Бәхет, яшәү илгә бүләк итеп,
Җиңү таңы тиздән кабыныр.

**2 нче укучы.**

Тиздән сүнәр гомерем, йөрәгемдә
Тоеп ялкын көчен.
Үлсәм үләм бөек хаклык өчен
Сөйгән халкым өчен.

**А.б.** Муса Җәлил шундый вәхшәт эчендә җырларын иҗат итеп, бер батырлык күрсәтсә, шул җырларны төрмәнең калын стеналары аша ирекккә чыгара алуы белән икенче батырлык эшли. Бу үлемсез җырлар безгә Мусаның авазы булып кына түгел, бәлки фашистлар җәзалаган миллионнарча корбаннарның, миллионнарча көрәшчеләрнең васыятьләре булып килеп житте.

*(Аудиоязмада салмак кына «Җырларым» көе яңгырый).*

**1 нче укучы.**

Туфрак күмәр тәнне, күмә алмас
Ялкынлы җыр тулы йөрәкне.
«Үлем» диеп әйтеп буламы соң
Җиңеп үлгән мондый үлемне.

**2 нче укучы**. Әйе, шагыйрь мәңге үлемсез. Муса Җәлилнең исеме бөтен планетага билгеле. Патриот шагыйрь исемен урамнар, мәктәпләр, китапханәләр йөртә. Аның исемендә театр, теплоход һәм пароходлар бар. Күк йөзендә Җәлил исеме белән аталган 3082 нче санлы кече планета нур сибә. Океан лайнеры каһарман шагыйрь исемен горур йөртә.

*(2 укучы залдан кереп китәләр).*

**А.б.** Ә хәзер, герой-шагыйрь Муса Җәлилгә багышланган уен кичәбезне башлыйбыз. Уенда 4 кешедән торган 2 команда катнаша. Командалар белән танышып үтик. Беренче команданың исеме «Кызыл ромашка», капитаны *(исемен әйтә)*. Икенче команданың исеме «Дуслык», капитаны *(исемен әйтә)*. Безнең жюри *(жюри әгъзалары белән таныштыра)*. Уеныбыз 5 турдан торачак.

1 нче тур. Сүзне командаларга бирәбез. Алар үзләре белән таныштырып китсеннәр әле. Уенны «Кызыл ромашка» командасы башлый. Уңышлар сезгә. *(Сүз командаларга бирелә, алар бер-берсен сәламлиләр).*

**А.б.** 2 нче тур «Муса Җәлил шигырьләрен беләсеңме?» дип атала. Экранда Муса Җәлил шигырьләреннән өзекләр күрсәтеләчәк, кайсы команда сорауга җавапны белә, шул команда кыңгырауны шалтыратып җавапны бирә. Башладык!

«Кырык чирне алып үз өстемә,
Аны саклап калыр идем мин». *(«Чулпанга»)*

«Сиңа миннән хәбәр китерсәләр,
Муса инде үлгән дисәләр». *(«Ышанма»)*

«Барыгыз болынга, балалар!
Йөгерегез, уйнагыз, көлегез!». *(«Чәчәкләр»)*

«Чәнечкеле тимер чыбык белән
Уратылган безнең йортыбыз». *(«Кошчык»)*

«Кичер мине, илем, синең бөек
Исемең белән килеп сугышка». *(«Кичер, илем!»)*

«Юл чатында ялгыз гына.
Үсеп утыра бер карт имән». *(«Имән»)*

«Җилләр, җилләр исегез,
Болытларны кисегез». *(«Җилләр»)*

«Минем бар маэмаем,
Кара борын акбаем... ». *(«Маэмай»)*

«Иртәнге таң нурыннан,
Уянды ромашкалар». *(«Кызыл ромашка»)*

*Ике тур буенча жюри нәтиҗәләр ясый.*

*Укучы «Бакчачы бабай» шигырен сөйли.*

**А.б.** 3 нче тур Муса Җәлилнең тормыш юлына һәм иҗатына багышлана. Экранда Муса Җәлилгә багышланган сораулар күрсәтеләчәк, кайсы команда сорауга җавапны алдан белә, шул команда кыңгырауны шалтыратып җавапны бирә. Башладык!

1. Муса Җәлил кайчан һәм кайда туган? *(1906 елда Оренбург өлкәсендәге Мостафа авылында).*

2. Муса Җәлилең беренче шигыре кайчан басылып чыга һәм ул ничек дип атала? *(1919 елда, «Бәхет» дип атала).*

3. Беренче шигырьләрен ул нинди псевдоним белән бастыра? *(«Кечкенә Җәлил»).*

4. Муса Җәлилнең беренче шигырьләр җыентыгы ничек дип атала, кайчан чыга? *(«Барабыз», 1925 елда).*

5. Муса Җәлил Казанга ничәнче елда килә? *(1922 елда).*

6. Муса Җәлил беренче шигырен ничә яшьтә яза? *(9 яшьтә).*

7. Муса Җәлил кызының исеме ничек? *(Чулпан).*

8. Муса Җәлил һәм җәлилчеләргә кайсы шәһәрдә суд була? *(Дрезден).*

9. Муса Җәлил сугышта кайсы фронтта катнаша? *(Волхов фронтында).*

10. «Моабит дәфтәре» кайда саклана? *(Милли музей фондында).*

11. «Җырларым» шигыренә көйне кем язган? *(Салих Сәйдәшев).*

12. Муса Җәлил беренче татар совет балалар журналларының җаваплы редакторы булып эшли, журналның исемнәрен атагыз. *(«Кечкенә иптәшләр» һәм «Октябрь баласы»).*

13. 1933–1934 елларда Муса Җәлил Мәскәүдә татар телендә чыга торган нинди газетаның әдәбият-сәнгать бүлеген җитәкли? *(«Коммунист»).*

14. Муса Җәлилнең рус телендәге сайланма шигырьләре җыентыгы беренче мәртәбә ничәнче елда һәм нинди исем белән басылып чыга? *(1934 елда, «Стихи Мусы Джалиля»).*

15. Муса Җәлилгә үлгәннән соң нинди исем бирелә? *(Советлар Союзы Герое дигән мактаулы исем бирелә).*

**А.б.** 4 нче тур «Әдәбиятта һәм сәнгатьтә Муса Җәлил образы» дип атала. Игътибар, экранга карыйбыз.

1. Сез Муса Җәлил турында иҗат ителгән нинди җырларны беләсез? *(«Муса» (Сибгат Хәким шигыре, Сара Садыйкова көе); «Торыгыз, Мусалар» (Сибгат Хәким шигыре, Җәүдәт Фәйзи көе); «12 батыр турында баллада» (Нури Арсланов шигыре, Рөстәм Яхин көе); «Яшь җәлилчеләр җыры» (Мәхмүт Хәсәнов шигыре, Рөстәм Яхин көе) һ.б.).*

2. «Муса Җәлил» симфониясенең авторы кем? *(Алмаз Монасыйпов).*

3. «Җәлил» операсын кемнәр иҗат иткән? *(Нәҗип Җиһанов музыкасы, Әхмәт Фәйзи либреттосы).*

4. Муса Җәлилнең «Сандугач һәм чишмә» әсәре буенча язылган вокал-симфоник поэманың авторы кем? *(Мирсәет Яруллин).*

5. «Моабит дәфтәрләре» буенча эшләнгән бер актлы балетның авторы кем? *(Глеб Успенский).*

6. Татарстан театрлары сәхнәләрендә Муса Җәлил образы тудырылган нинди әсәрләр куелды? *(«Муса Җәлил» (Нәкый Исәнбәт); «Үлмәс җыр» (Риза Ишморат); «Җәлил» (Нәҗип Җиһанов); «Моңлы бер җыр» (Туфан Миңнуллин) һ.б.).*

7. Татарстан артистларыннан кемнәр театр сәхнәләрендә Муса Җәлил ролен башкарды? *(Фуат Халиков, Идеал Ишбүләков, Николай Проваторов, Ренат Таҗетдинов һ.б.).*

8. «Моабит дәфтәре» кинофильмында Муса Җәлил ролен кем башкарды? *(Россиянең халык артисты Пётр Чернов).*

9. Муса Җәлилгә багышланган нинди документаль фильмнар беләсез? *(«Тормыш – җыр», «Җәлил. Көрәш сәхифәләре» һ.б.).*

10. Татар сүз осталарыннан кемнәргә Татарстан комсомолының Муса Җәлил исемендәге премиясе бирелде? *(Илдар Юзеев, Гази Кашшаф, Рафаэль Мостафин, Ренат Харис, Роберт Миңнуллин, Разил Вәлиев, Равил Фәйзуллин, Фәнис Яруллин һ.б.).*

11. Кайсы рәссам-сынчылар үз иҗатларында Муса Җәлил образын тудырдылар? *(Бакый Урманче, Харис Якупов, Ефим Симбирин, Васил Маликов, Луис Ортега (испан рәссамы), Николай Колесников, Канәфи Нәфыйков, Владимир Цигаль һәм Лев Голубовский (Казанда М.Җәлил һәйкәле), Виктор Рогожин, Искәндәр Рәфыйков, Юрий Лысогорский һ.б.).*

12. Муса Җәлил образы сурәтләнгән сынлы сәнгать әсәрләреннән нindиләрне беләсез? *(Харис Якуповның «Хөкем алдыннан»; Әмир Вәлиәхмәтовның «Герой Муса Җәлил Моабит төрмәсендә»; Абрек Абзгильдинның «Багышлау»; Искәндәр Рәфыйковның «Җәлилчеләр»;*

*Рада Нигъмәтуллинаның «Моабитта төш»; Фәрит Якуповның «Шагыйрь һәм палач» һ.б.).*

**А.б.** 5 нче турга күчәбез. «Кайсы команда тапкыррак?» уены. «Сандугач һәм чишмә» сүзләреннән яңа сүзләр төзеп язарга. Бу биремгә 2 минут вакыт бирелә.

*(Аудиоязмада «Сәгать» җыры ишетелә).*

**А.б.** 6 нчы тур – капитаннар ярышы. Экранда сораулар һәм шул сорауга берничә вариантта җаваплар күрсәтеләчәк. Сезгә дөрес җавапны сайлап алырга кирәк булачак.

1 нче командага сораулар:

1. Бу юллар кайсы шигырьдән?

«Ул ялгыз яши,
Чыгармый бала,
Менә шунлыктан
Ямансу аңа!»

*а) Яз җыры*
*б) Әтәч*
*в) Сандугач һәм чишмә*
***<u>г) Күке</u>***

2. Бу юллар кайсы шигырьдән?

«Ул кояш белән бергә кузгала,
Көрәген ала, җиңен сызгана»

а*) Маэмай*
*б) Көз җитте*
***<u>в) Бакчачы</u>***
*г) Яз җыры*

3. Муса Җәлилнең «Сәгать» шигырендәге малайның исеме?

***<u>а) Марат</u>***
*б) Абдулла*
*в) Закир*
*г) Зариф*

4. Муса Җәлил кызының исеме?

*а) Рәхимә*
***б) Чулпан***
*в) Әминә*
*г) Зәйнәп*

5. Бу юллар кайсы шигырьдән?

«Әйдәгез, дуслар,
Аны терелтик,
Җылы бүлмәгә,
Мәктәпкә илтик»

*а) Карак песи*
***б) Куян***
*в) Маэмай*
*г) Әтәч*

2 нче командага сораулар:

1. Муса Җәлилнең әнисенең исеме?

*а) Зәйнәп*
***б) Рәхимә***
*в) Әминә*
*г) Чулпан*

2. Муса Җәлилнең «Бакчачы» шигырендәге төп герой?

***а) Бабай***
*б) Малай*
*в) Кыз*
*г) Әби*

3. Нинди сүз төшеп калган?

«Юл чатында ялгыз гына
Үсеп утыра бер карт...»
*а) Тал*

***б) Имән***
*в) Алмагач*
*г) Каен*

4. Муса Җәлил – ...

*а) сәхнә остасы*
*б) талантлы композитор*
*в) танылган рәссам*
***г) герой-шагыйрь***

5. Бу юллар кайсы шигырьдән?

«Бакчага килдек,
Ашыга-ашыга»

***а) Әтәч***
*б) Сандугач һәм Чишмә*
*в) Күке*
*г) Сәгать*

*Жюри бәйгегә нәтиҗәләр ясый. Җиңүче команда билгеләнә.*

**А.б.** Муса Җәлил – татар халкының, алай гына да түгел, илебез халыкларының да йөз аклыгы ул. Үзен аямыйча кулындагы коралы белән дә, каләме белән дә дошманга каршы көрәшкән шагыйрь беркайчан да онытылмас, аның тормыш юлын, әдәби мирасын өйрәнү эшләре буыннан-буынга дәвам итәр.

Кабат очрашуларга кадәр дип, сезнең белән саубуллашабыз!

**Файдаланылган чыганаклар:**

1. Тазиева Р.Р. «Тамчы шоу»: Муса Җәлил иҗатына багышланган уен. – Керү режимы: https://урок.рф/library/mlilg_bagishlangan_kich_tamchi_shou_uenistcena_213701.html

2. Муса Җәлил иҗатына багышланган ярыш: КВН-дәрес (5–8 сыйныф укучылары өчен). – Керү режимы: https://compedu.ru/publication/musa-zh-lil-izhaty-kvn-d-res.html

3. Хәйдәрова Р. Кайда? Кайчан?: [М.Җәлилгә багышланган әдәби викторина] // Мәгариф. – 1996. – № 2. – Б. 19.

4. «Муса Җәлил – герой-шагыйрь»: викторина, квиз: – Керү режимы: https://vneuroka.ru/viktoriny/viktorina-kviz-musa-zhalil-geroj-shagyjr-tatar-telende-voprosy-i-otvety-s-podskazkami-intellektualnaya-igra-na-vremya-0-0-100.html

5. Әдәбиятта һәм сәнгатьтә Муса Җәлил образы: (X–XI класслар өчен викторина сораулары) // Мәгариф. – 2001. – № 2. – Б. 23.

## Муса Җәлилгә багышланган шигырьләр

1. Арслан Н. Унике батыр турында баллада: [шигырь] // Җәлил М. Сайланма әсәрләр: шагыйрь турында истәлекләр / М. Җәлил; [төз., кереш сүз язучы Ф. Г. Галимуллин]. – Казан: Тарих, 2004. – Б. 561.

2. Ваһабзадә Б. (Бәхтияр). Очыгыз, тулпарларым!: [М.Җәлилгә багышланган поэма; авторы – Азәрбәйҗанның халык шагыйре] / Б.Ваһабзадә; тәрҗ. Р. Харис // Безнең мирас. – 2021. – № 5. – Б. 32–36.

3. Гатауллин Р. Җәлил рухы: [шигырь] // Идел. − 2018. − № 6. − Б. 57.

4. Гомерем минем моңлы бер җыр иде: [татар шагыйрьләренең Муса Җәлилгә багышланган шигырьләре] // Ватаным Татарстан. − 2006. − 10 февр.

5. Дудин М. Муса Җәлил истәлегенә: (М. Җәлилгә багышланган шигырь) / тәрҗ. Р. Миңнуллин // Җәлил М. Сайланма әсәрләр: шагыйрь турында истәлекләр / М. Җәлил; [төз., кереш сүз язучы Ф.Г.Галимуллин]. – Казан: Тарих, 2004. – Б. 560.

6. Зәйдулла Р. Җәлил кояшы: [җәлилчеләр батырлыгы тур. шигырь] // Казан утлары. − 2016. – № 2. – Б. 117.

7. Зәйдулла Р. Җәлил: [шигырь] // Казан утлары. − 2015. − № 1. − Б. 54.

8. Зәйдулла Р. Җәлил: [шигырь] // Казан утлары. − 2013. − № 10. − Б. 50.

9. Зәйдуллин Р. Җәлил кояшы: (М. Җәлилгә багышланган шигырь) // Җәлил М. Сайланма әсәрләр: шагыйрь турында истәлекләр / М. Җәлил; [төз., кереш сүз язучы Ф. Г. Галимуллин]. – Казан: Тарих, 2004. – Б. 564.

10. Зөлфәт. ...Җырлый белмиләр бөркетләр: (М. Җәлилгә багышланган шигырь) // Җәлил М. Сайланма әсәрләр: шагыйрь турында истәлекләр / М. Җәлил; [төз., кереш сүз язучы Ф.Г.Галимуллин]. – Казан: Тарих, 2004. – Б. 563.

11. Корбан Р. Җәлил: [шигырь] // Казан утлары. − 2017. – № 1. – Б. 129.

12. Лерон Л. Җәлилчеләрне уйлап: [шигырь] // Безнең мирас. − 2014. − № 8. − Б. 3.

13. Лерон Л. Җәлилчеләрне уйлап: [җәлилчеләр тур. шигырь] // Казан утлары. – 2016. – № 2. – Б. 117.

14. Мөслимова Ф. Рухларына – дога...: [җәлилчеләр тур. шигырь] // Казан утлары. – 2016. – № 2. – Б. 116.

15. Мирза М. Халкым мәңгелеккә хакы барын Җәлилләре белән дәлилләр!: Мәңгелекне хаклап; «Истанбул этюдлары» циклыннан; Тәкъдир күрсәтте көчен; «Адәм баласы» циклыннан: [шигырьләр] / М.Мирза // Идел. − 2010. – № 8. – Б. 6–8.

16. Морат Г. Соңгы җыр: [М. Җәлилгә багышланган шигырь] // Казан утлары. – 2016. – № 2. – Б. 116–117.

17. Моратов Г. Җәлил һәйкәле янында уйлану: (М. Җәлилгә багышланган шигырь) // Җәлил М. Сайланма әсәрләр: шагыйрь турында истәлекләр / М. Җәлил; [төз., кереш сүз язучы Ф.Г.Галимуллин]. – Казан: Тарих, 2004. – Б. 565.

18. Нәҗми А. Муса Җәлил: [шагыйрьгә багышланган шигырь] // Идел. − 2009. − № 2. − Б. 63.

19. Нәҗми Н. Кичер мине: (М. Җәлилгә багышланган шигырь) // Җәлил М. Сайланма әсәрләр: шагыйрь турында истәлекләр / М.Җәлил; [төз., кереш сүз язучы Ф. Г. Галимуллин]. – Казан: Тарих, 2004. – Б. 560.

20. Низами Р. Корыч дивар: [шигырь; М.Җәлилнең тууына 110 ел] // Казан утлары. – 2016. – № 2. – Б. 115.

21. Рафиков М. Ике сын: (М. Җәлилгә багышланган шигырь) // Җәлил М. Сайланма әсәрләр: шагыйрь турында истәлекләр / М.Җәлил; [төз., кереш сүз язучы Ф. Г. Галимуллин]. – Казан: Тарих, 2004. – Б. 563.

22. Сәлахов Р. Шагыйрь йөрәге: [М. Җәлилгә багышланган шигырь] // Казан утлары. – 2016. – № 2. – Б. 118–119.

23. Сөләйманов Б. Язмышка без кәфен кидермәбез. Җәлилчеләр истәлегенә: [шигырь] // Мәйдан. − 2018. − № 5. − Б. 69.

24. Фәйзуллин Р. Бердәнбер юл түгел тормышта...: [шигырь] // Җәлил М. Сайланма әсәрләр: шагыйрь турында истәлекләр / М.Җәлил; [төз., кереш сүз язучы Ф. Г. Галимуллин]. – Казан: Тарих, 2004. – Б. 562.

25. Фәйзуллин Р. Җәлил һәйкәле: [шигырь] // Казан утлары. − 2011. − № 12 . − Б. 5.

26. Харис Р. Җәлил һәйкәленә: [шигырь] // Идел. − 2019. − № 4. − Б. 35.

27. Харис Р. Сонетлар: Шикләнүләр сонеты; Йомшак тәртип сонеты; Пушкин сере сонеты; Аваз сонеты; Ихласлык сонеты; Җәлил каны турында сонет; Аның күзләре турында сонет; Ак кәгазь сонеты; Казма зираты сонеты: [сонетлар] / Р. Харис // Казан утлары. − 2011. – № 5. – Б. 36–42.

28. Хәким С. ...Төштә нәрсә күргәнлеген беләм: (М. Җәлилгә багышланган шигырь) // Җәлил М. Сайланма әсәрләр: шагыйрь турында истәлекләр / М. Җәлил; [төз., кереш сүз язучы Ф. Г. Галимуллин]. – Казан: Тарих, 2004. – Б. 559.

29. Юзеев И. Читләрнең үз бәясе: [шигырь] // Җәлил М. Сайланма әсәрләр: шагыйрь турында истәлекләр / М. Җәлил; [төз., кереш сүз язучы Ф. Г. Галимуллин]. – Казан: Тарих, 2004. – Б. 566.

## Муса Җәлил иҗатына багышланган сценарийлар, методик әдәбият һәм Интернет-чыганаклар исемлеге


1. Абдуллина С.Г. «Синең җырлар, Муса, үз илеңдә мәңге сүнмәс яшәү таптылар!»: кичә. – Керү режимы: https://infourok.ru/sine-irlar-musa-z-ilend-mge-snms-yash-taptilar-musa-lilne-iatina-bagishlangan-dbi-muzikal-kich-klass-2424575.html
2. Әдәбиятта һәм сәнгатьтә Муса Җәлил образы: (X–XI класслар өчен викторина сораулары) // Мәгариф. – 2001. – № 2. – Б. 23.
3. Әхмәдуллина Г. Муса Җәлил иҗаты – дөнья матбугатында: [герой-шагыйрь М.Җәлилне искә алу көне] // Мәгариф. – 2009. – № 2. – Б. 5–7.
4. Әхмәдуллина Р. Муса Җәлилнең «Ана бәйрәме» шигырен сәхнәләштерү: (рус мәктәбенең рус төркемендә Җиңү көненә багышланган әдәби-музыкаль кичә. IV сыйныф) // Мәгариф. – 2019. – № 6. – Б. 62–64.
5. Әхмәтшина Ф. Гомерем минем моңлы бер җыр иде, үлемем дә яңрар җыр булып: [М.Җәлилнең тууына 100 ел тулуга багышланган сценарий] // Фән һәм мәктәп=Наука и школа. – 2006. – № 2. – Б. 2–5.
6. Гомерем минем моңлы бер җыр иде...: [патриот-шагыйрь М.Җәлилгә багышланган әдәби викторина] // Сабантуй. – 2006. – 11 февраль.
7. Гыйләҗев И. Үлемсез исем: [әдәбият дәресләре; автор Чаллы пед. ин-тында һәм 2 нче татар гимназиясендә татар әдәбиятын укыта; аның М.Җәлил иҗатына багышланган бер дәрес үрнәге бирелә] // Фән һәм мәктәп=Наука и школа. – 1999. – № 1. – Б. 92–96.
8. Данилюк Н. Җыр өйрәтте аны...: (Н.Җиһановның «Җәлил» операсында татар шагыйре Муса Җәлил батырлыгы. VII класс өчен дәрес үрнәге. Автор Чистай шәһәренең гомуми белем бирү гимназиясеннән) // Мәгариф. – 1994. – № 6. – Б. 43–44, 48.
9. «Җир йөзе шундый киң, күңелле һәм якты»: Муса Җәлилгә багышланган сыйныфтан тыш кичә. – Керү режимы: https://infourok.ru/mlilg-bagishlangan-kichg-scenariy-2045632.html

10. Залялова Р.А. «Герой шагыйрь – Муса Жәлил»: сценарий. – Керү режимы: https://edu.tatar.ru/sovetcki/page86044.htm/page3019839.htm
11. Зарипова Х.М. Халкыбыз каһарманы: Муса Җәлил иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичә. – Керү режимы: https://multiurok.ru/files/musa-zh-lil-izhatyna-bagyshlangan-d-bi-muzykal-kic.html
12. Ибәтов Р. «Алар мәңге үлемсез!»: әдәби-музыкаль композиция: [Муса Җәлилнең тууына – 95 ел] // Мәгариф. – 2001. – № 2. – Б. 86–88.
13. Йолдызлы сәгать: Муса Җәлил иҗатына багышланган әдәби чара. – Керү режимы: https://kopilkaurokov.ru/vneurochka/meropriyatia/ioldyzly_s_ghat_musa_zh_lilgh_baghyshlanghan
14. «Көрәшкә бир бөтен гомереңне»: Муса Җәлилгә багышланган әдәби-музыкаль кичә. – Керү режимы: https://nsportal.ru/shkola/rodnoy-yazyk-i-literatura/library/2016/01/17/korshk-bir-boten-gomerenne-musa-zhlilg
15. Мөхәммәтгәрәева Г. Җыр булып яши күңелдә: [патриот-шагыйрь М.Җәлилнең 100 еллыгына багышланган кичә үткәрү өчен сценарий] // Мәгърифәт. – 2006. – 21 гыйнвар.
16. Минһаҗева С. «Чәчәк кенә, гөл генә безнең туган ил генә»: [М.Җәлил иҗатына багышланган сценарий] // Мәгариф. – 2006. – № 2. – Б. 42.
17. Миңнеәхмәтова Т. Муса Җәлил иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичә // Башкортостан укытыусыһы. – 1996. – № 1. – Б. 70–74.
18. Мостафин Р. Ул үз халкын бөек итте: [герой-шагыйрь М.Җәлилнең тууына 100 ел тулу уңаеннан] // Татарстан. – 2006. – № 2. – Б. 28–29.
19. Муса Джалиль. Биобиблиографический справочник = Муса Җәлил. Биобиблиографик белешмәлек. – Керү режимы: https://kitaphane.tatarstan.ru/jal.htm
20. «Муса Җәлил»: кроссчайнворд // Тулпар. – 1997. – № 3. – Б. 80.
21. Муса Җәлилгә багышланган әдәби викторина (электрон презентация). – Керү режимы: https://belem.ru/node/7159

22. Муса Җәлилгә багышланган кичә. – Керү режимы: https://nsportal.ru/shkola/rodnoy-yazyk-i-literatura/library/2016/11/25/musa-zhlilg-bagyshlangan-kich
23. «Муса Җәлил – батыр рухлы шагыйрь»: әдәби-музыкаль кичә. – Керү режимы: https://infourok.ru/dbi-muzikal-kich-m-lil-batir-ruhli-shagiyr-1243377.html
24. Муса Җәлил иҗаты: КВН-дәрес (5–8 сыйныф укучылары өчен). – Керү режимы: https://compedu.ru/publication/musa-zh-lil-izhaty-kvn-d-res.html
25. Муса Җәлил иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичә. – Керү режимы: https://multiurok.ru/files/musa-zh-lil-izhatyna-bagyshlangan-d-bi-muzykal-kic.html
26. Муса Җәлил турында фильм. – Керү режимы: https://belem.ru/node/5499
27. «Муса Җәлил – һаман безнең арада» (башлангыч һәм урта сыйныфлар өчен): шагыйрьнең иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичә. – Керү режимы: https://sadykovavenera.ucoz.com/load/ukytuchylar_chen/razrabotki_urokov_i_vneklassnykh_meroprijatij/musa_lil_aman_bezne_arada/3-1-0-6
28. Низамиева Р. Исемең калды моңлы бер җыр булып, үзеңнән соң килгән буынга: [Муса Җәлилнең туган көненә багышланган әдәби-музыкаль кичә] // Ачык дәрес. – 2010. – гыйнвар. – Б. 19–20.
29. Нуриева Л.М. «Җыр һәм Муса Җәлил»: тикшерү эше. – Керү режимы: https://nsportal.ru/ap/library/literaturnoe-tvorchestvo/2016/04/09/issledovatelskaya-rabota-zhyr-hm-musa-zhlil
30. Рәхимҗанова Ә.М. «Серле йомгак эзеннән» тапшыруында «Муса Җәлил халык күңелендә яши» темасына ток-шоу. – Керү режимы: https://belem.ru/node/5736
31. Рәхмәтуллина Р. Мусалар елмаеп үлделәр...: (өлкән сыйныф укучылары өчен Р.Мостафинның «Җәлилчеләр» әсәре буенча класстан тыш уку дәресе) // Фән һәм мәктәп=Наука и школа. – 2000. – № 1–2. – Б. 161–163.

32. Садыкова В. А. Муса Җәлилгә багышланган әдәби-музыкаль кичә / В.А. Садыкова // Башкортостан укытыусыһы. – 2013. – № 2. – Б. 54–55.
33. Садыйкова В. Ә. «Бар җырымны илгә багышладым, гомремне дә бирәм халкыма...»: [герой-шагыйрь М.Җәлилнең тууына 110 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә] / В.Ә. Садыйкова // Башкортостан укытыусыһы. – 2016. – № 2. – Б. 43–45.
34. Сәетова Л. «Беркем дә онытылмый, һичнәрсә истән чыкмый!»=«Никто не забыт, ничто не забыто!»: (Муса Җәлилгә багышлап Мәскәүнең 1186 нчы мәктәбендә татар һәм рус телләрендә үткәрелгән әдәби-иҗат кичәсе сценарие) // Мәгариф. – 2018. – № 2. – Б. 29–33; (Керү режимы: https://magarif-uku.ru/news/teachers-room_tt/berkem-de-onytylmyjj-hichnerse-isten)
35. Сценарий литературного праздника, посвящённого юбилею Мусы Джалиля (Примерный план подготовки и проведения праздника). – Керү режимы: https://kitaphane.tatarstan.ru/jal_8.htm
36. Төхбәтуллина Л.Ф. Муса Җәлилгә багышланган әдәби викторина. – Керү режимы: https://belem.ru/node/7159
37. Усманова Н. «Гомерем минем моңлы бер җыр иде... »: әдәби-музыкаль кичә: [Муса Җәлил] // Фән һәм мәктәп=Наука и школа. – 2000. – № 1–2. – Б. 164–166.
38. Фёдорова Л. «Яшәү хозурлыгы хөрлектә, гомер озынлыгы ирлектә...»: [герой-шагыйрь Муса Җәлилнең тууына – 105 ел; дәрес-проект] / Л. Фёдорова // Мәгариф. – 2011. – № 2. – Б. 7–9.
39. Хәбибуллина Р.К. «Без – Җәлил оныклары»: әдәби-музыкаль кичә. – Керү режимы: https://belem.ru/node/3332
40. Хәйбуллина М.Ә. Муса Җәлилнең иҗатына багышланган бәйрәм кичәсе. – Керү режимы: http://sabyem.ru/?p=7993
41. Хәйдәрова Р. Кайда? Кайчан?: [М.Җәлилгә багышланган әдәби викторина] // Мәгариф. – 1996. – № 2. – Б. 19.
42. Хәйруллина Р.М. Тарихларда укып ятларлык: Муса Җәлилгә багышланган әдәби-музыкаль кичә. – Керү режимы: https://nsportal.ru/shkola/rodnoy-yazyk-i-literatura/library/2012/08/28/tarikhlarda-ukyp-yatlarlyk-musa-zhlilnen
43. Шәйхетдинова Г.Н. Герой-шагыйрь Муса Җәлилнең 115 еллыгына багышланган әдәби-музыкаль кичә. – Керү режимы:

https://nsportal.ru/shkola/rodnoy-yazyk-i-literatura/library/2021/03/11/geroy-shagyyr-musa-zhlilnen-115-ellygyna

44. Юсупова Л.Г. «Герой-шагыйрь Муса Җәлил»: М. Җәлилнең иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичә. – Керү режимы: https://nsportal.ru/shkola/rodnoy-yazyk-i-literatura/library/2023/01/15/razrabotka-meropriyatiya-geroy-shagyyr-musa-0

## **Муса Җәлил тормышы һәм иҗаты матбугат битләрендә**

*(2010–2025 еллар)*


1. Абзалина Р. Шәфкать туташы Хәят: [Бөек Ватан сугышында фашистлар тылында Белоруссиядә Муса Җәлил б-н очрашкан шәфкать туташы Хәят Сафиуллина турында] // Мәдәни җомга. – 2020. – 21 август (№ 33). – Б. 19.
2. Агеева Л. Егерме ел үткәч / Л. Агеева // Татарстан. – 2011. – № 10. – Б. 60–63.
3. Агиш С. Якташлар: [шагыйрь М.Җәлил турында повестьтан өзек] / С. Агиш // Мәйдан. Чаллы. – 2016. – № 2. – Б. 19–27.
4. Аймәт Р. Җәлил улы: [М.Җәлилнең беренче, бердәнбер һәм иң яраткан улы подполковник Альберт Җәлилов һәм аның әнисе Рауза Хисмәтуллина турында] // Мәйдан. Чаллы. – 2018. – № 10. – Б. 16–20.
5. Арсланов Л. Җәлил һәм Ялкайн: [Муса Җәлилнең мари язучысы Яныш Ялкайн (Ялкаев Яныш Ялкаевич) белән дуслыгы турында] / Л. Арсланов // Мәдәни җомга. – 2011. – 26 август (№ 34). – Б. 15.
6. Арсланов М.Г. Муса Җәлил – драматург һәм театр тәнкыйтьчесе // Гасырлар авазы=Эхо веков. – 2017. – № 3–4. – Б. 176–181.
7. Ашрапова Г.Р. Муса Җәлилнең дәреслектә бирелгән шигырьләрен анализлау алымнары // Актуальные проблемы инновационного педагогического образования. – 2019. – № 3 (12). – Б. 29–31.
8. Әбсәләмова Ф. Җәлил сеңлесе: [Муса Җәлилнең сеңлесе Хәдичә Җәлилова турында] / Ф. Әбсәләмова // Халкым минем. – 2016. – сентябрь (№ 9 (64)). – Б. 7.
9. Әпсәләмова А. Әтисе кызы: [шагыйрь М.Җәлилнең кызы Ч.Җәлилова әнисе турында истәлекләр белән уртаклаша] / А. Әпсәләмова // Идел. – 2016. – № 2. – Б. 60–63.
10. Әскәров Н. Муса Җәлилнең «Сандугач һәм чишмә» балладасына анализ: [VI сыйныф; татар әдәбияты дәресе] // Мәгариф. – 2018. – № 2. – Б. 24–27.
11. Әстерханда Җәлил һәйкәле: [ТР Президенты Р.Миңнеханов, Әстерхан өлкәсе губернаторы А.Жилкин б-н берлектә, татар герой-

шагыйре Муса Җәлилгә һәйкәл ачу тантанасында катнашты] // Мәдәни җомга. – 2017. – 19 май (№ 19). – Б. 4.
12. Әхмәтҗанова Ф. «Хуш, Минзәлә, синдә кунак булдым... »: [Минзәләдәге Муса Җәлил музее турында] / Ф. Әхмәтҗанова // Ватаным Татарстан. – 2013. – 16 апрель (№ 61). – Б. 3.
13. Әһлетдинова Л. «Мин тез чүкмәм, катыйль, синең алда...»: [Х.Якуповның «Хөкем алдыннан» исемле картинасы турында] / Л. Әһлетдинова // Мәгариф=Просвещение. – 2012. – № 8. – Б. 64–66.
14. Бакиров М. Шигъри сүз куәтенең сере: [Муса Җәлилнең тууына 110 ел. Иҗаты турында] / М. Бакиров // Мәдәни җомга. – 2016. – 12 февраль (№ 5). – Б. 21.
15. Баттал Р. Җәлилне белүчеләр: [шагыйрь М.Җәлил турында истәлекләр] / Р. Баттал // Мәйдан. Чаллы. – 2015. – № 2. – Б. 44–46.
16. Баттал С. Көндәлекләрдән: [М.Җәлил турында истәлек (1934 ел). Шаян сәхифә] / С. Баттал // Казан утлары. – 2015. – № 10. – Б. 178–179.
17. Баттал С. Муса Җәлилгә багышланган мәзәкләр: [Р.Батулланың «Тузга язмаган хәлләр» китабыннан алынды] / С. Баттал // Безнең мирас. – 2016. – № 2. – Б. 118.
18. Баттал С. Сакаллы Җәлил: [шагыйрь М.Җәлилгә бәйле мәзәк] / С. Баттал // Безнең мирас. – 2015. – № 12. – Б. 112.
